Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Ямбакты авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 134 « 29 » ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 24 октябрендәге 101-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 05 декабрендәге 104 номерлы, 2024 елның 31 январендәге 110-1 номерлы, 2024 елның 22 февралендәге 111-2 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 24 октябрендәге 101-1 номерлы карарына (2023 елның 05 декабрендәге 104 номерлы, 2024 елның 31 январендәге 110-1 номерлы, 2024 елның 22 февралендәге 111-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктының өченче абзацында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш»;

1.2. 1.1 пунктның дүртенче абзацында "һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш" сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Ямбактыторак пунктындагы мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И.Э.Галәветдинов